# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2017 года

### Статья 1

Внести в статью 19 Закона Республики Татарстан от 7 июня 2004 года № 37-ЗРТ «О Счетной палате Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 65-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 6; 2011, № 10 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 6 (I часть); 2016, № 4) изменение, дополнив ее частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Должностные лица Счетной палаты обязаны соблюдать ограничения, запреты, исполнять обязанности, которые установлены Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», Федеральным законом от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», Федеральным законом от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами».».

### Статья 2

Внести в статью 26 Закона Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (I часть), № 27 (I часть) изменение, дополнив ее частью $7^1$ следующего содержания:

«7[1]. Контракт с главой местной администрации может быть расторгнут в судебном порядке на основании заявления Президента Республики Татарстан в связи с несоблюдением ограничений, запретов, неисполнением обязанностей, которые установлены Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», Федеральным законом от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», Федеральным законом от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами», выявленными в результате проверки достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемых в соответствии с законодательством Российской Федерации о противодействии коррупции.».

**Статья 3**

Внести в статью 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 5, № 12 (I часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 12 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (I часть); Официальный портал правовой информации Республики Татарстан (PRAVO.TATARSTAN.RU), 6 июля 2017 года) следующие изменения:

1) дополнить частью $6^1$ следующего содержания:

«$6^1$.Член комиссии с правом решающего голоса, работающий в комиссии на постоянной (штатной) основе, освобождается от обязанностей члена комиссии в случае несоблюдения ограничений, запретов, неисполнения обязанностей, которые установлены Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», Федеральным законом от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», Федеральным законом от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами».»;

2) в части 10 слова «указанным в частях 6 и 8 настоящей статьи» заменить словами «указанным в частях 6, $6^1$ и 8 настоящей статьи»;

3) абзац первый части $13^1$ изложить в следующей редакции:

«$13^1$. Члену Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан с правом решающего голоса, члену иной избирательной комиссии, действующей на постоянной основе и являющейся юридическим лицом, с правом решающего голоса,

работающим в указанных комиссиях на постоянной (штатной) основе, запрещается:»;

4) дополнить частью $13^4$ следующего содержания:

«$13^4$. Член Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан с правом решающего голоса, член иной избирательной комиссии, действующей на постоянной основе и являющейся юридическим лицом, с правом решающего голоса, работающие в указанных комиссиях на постоянной (штатной) основе, обязаны соблюдать ограничения, запреты, исполнять обязанности, которые установлены Федеральным законом от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», Федеральным законом от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», Федеральным законом от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами».».

**Статья 4**

Внести в Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 17 (I часть) следующие изменения:

1) пункт 3 части 1 статьи 16 изложить в следующей редакции:

«3) заниматься предпринимательской деятельностью лично или через доверенных лиц, участвовать в управлении коммерческой организацией или в управлении некоммерческой организацией (за исключением участия в управлении политической партией; участия в съезде (конференции) или общем собрании иной общественной организации, жилищного, жилищно-строительного, гаражного кооперативов, садоводческого, огороднического, дачного потребительских кооперативов, товарищества собственников недвижимости; участия на безвозмездной основе в управлении указанными некоммерческими организациями (кроме политической партии) в качестве единоличного исполнительного органа или вхождения в состав их коллегиальных органов управления с разрешения представителя нанимателя (работодателя) в порядке, установленном муниципальным правовым актом), кроме случаев, предусмотренных федеральными законами, и случаев, если участие в управлении организацией осуществляется в соответствии с законодательством Российской Федерации от имени органа местного самоуправления;»;

2) статью 18 дополнить частями 11 – 14 следующего содержания:

«11. Граждане, претендующие на замещение должности главы местной администрации по контракту, и лицо, замещающее указанную должность, представ-

ляют сведения о своих доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, а также сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера своих супруг (супругов) и несовершеннолетних детей Президенту Республики Татарстан в порядке, установленном законом Республики Татарстан.

12. Сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представленные лицом, замещающим должность главы местной администрации по контракту, размещаются на официальном сайте органа местного самоуправления в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» и (или) предоставляются для опубликования средствам массовой информации в порядке, определяемом муниципальными правовыми актами.

13. Проверка достоверности и полноты сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, представляемых в соответствии с частью 11 настоящей статьи, осуществляется по решению Президента Республики Татарстан в порядке, установленном законом Республики Татарстан.

14. При выявлении в результате проверки, осуществленной в соответствии с частью 13 настоящей статьи, фактов несоблюдения лицом, замещающим должность главы местной администрации по контракту, ограничений, запретов, неисполнения обязанностей, которые установлены Федеральным законом «О муниципальной службе в Российской Федерации», Федеральным законом от 3 декабря 2012 года № 230-ФЗ «О контроле за соответствием расходов лиц, замещающих государственные должности, и иных лиц их доходам», Федеральным законом от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами», Президент Республики Татарстан обращается с заявлением о досрочном прекращении полномочий лица, замещающего должность главы местной администрации по контракту, или применении в отношении его иного дисциплинарного взыскания в орган местного самоуправления, уполномоченный принимать соответствующее решение, или в суд.».

**Статья 5**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
19 июля 2017 года
№ 55-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4), түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

“$4^1$. Хисап палатасының вазыйфаи затлары “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәргә тиеш.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш);

2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

“$7^1$. Җирле администрация башлыгы белән контракт коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты мөрәҗәгате нигезендә суд тәртибендә өзелергә мөмкин.”.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш), Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2017 елның 6 июле) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

“$6^1$. Комиссиядә даими нигездә (штатта) эшләүче хәлиткеч тавыш хокукына ия комиссия әгъзасы “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта комиссия әгъзасы йөкләмәләрен үтәүдән азат ителә.”;

2) 10 өлештә “әлеге статьяның 6 һәм 8 өлешләрендә күрсәтелгән” сүзләрен “әлеге статьяның 6, $6^1$ һәм 8 өлешләрендә күрсәтелгән” сүзләренә алмаштырырга;

3) $13^1$ өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$13^1$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзасына, даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып торучы башка сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзасына түбәндәгеләр тыела:”;

4) түбәндәге эчтәлекле $13^4$ өлеш өстәргә:

“$13^4$. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзасы, даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып торучы башка сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия даими нигездә (штатта) эшләүче әгъзасы “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәргә тиеш.”.

**4 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) федераль законнарда каралган очраклардан һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән башкарылган очраклардан тыш, шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерциячел оешма белән идарә итүдә яисә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашу; башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу; күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партияләрдән тыш) белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез нигездә катнашу яисә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән аларның коллегиаль идарә органнары составына керү моңа керми);”;

2) 18 статьяда түбәндәге эчтәлекле 11 – 14 өлешләр өстәргә:

“11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм күрсәтелгән вазыйфаны биләүче зат Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра.

12. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырылган белешмәләр җирле үзидарә органының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла һәм (яисә) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрелә.

13. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге статьяның 11 өлеше нигезендә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары белән гамәлгә ашырыла.

14. Әлеге статьяның 13 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәве ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында яисә аңа карата башка дисциплинар чара күрү турында тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.”.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 19 июль
№ 55-ТРЗ